ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРНЯКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Лесная, д. 44А, п.Урняк,
Арский муниципальный район, 422019

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ҮРНӘК
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Урман урамы, 44А йорты, Үрнәк авылы,
Арча муниципаль районы, 422019

Тел. (84366)51-4-93, факс (84366)51-4-93. E-mail: Urn.Ars@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«22» апрель 2019 ел** **№ 7**

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә нокталары кагыйдәләрен һәм урамда сатуны оештыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 28 мартындагы 4 номерлы Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт җайга салуы нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законы, «Контроль-касса техникасы кулланмыйча түләү карталары файдаланып акчалата исәп-хисап һәм (яки) исәп-хисап башкару тәртибе турында» 2008 елның 6 маендагы 359 нчы номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә Үрнәк башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә нокталары кагыйдәләрен һәм урамда сатуны оештыру Тәртибен раслау турында» 2017 елның 28 мартындагы 4 номерлы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә нокталары кагыйдәләрен һәм урамда сатуны оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.2. пунктының 2 кызыл юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Стационар булмаган сәүдә ноктасы – инженер-техник тәэмин ителеш челтәренә тоташтыру (технологик тоташтыру) булуы яки булмавына бәйсез рәвештә җир кишәрлеге белән ныклап бәйләнмәгән вакытлыча корылма яки вакытлыча конструкцияне тәшкил итүче сәүдә ноктасы, шул исәптән күчмә корылма.»;

2) 2.11. пунктын түбәндәге редакциядә бәян иәргә:

«2.11. Сатучы сатыла торган товар өчен бердәм һәм ачык итеп ясалган,

үз эченә товарның исемен, сортын (булган очракта), авырлыгын яки үлчәү берәмлеген алган бәяләр белешмәсе булуын тәэмин итәргә тиеш. Бәяләр белешмәсен кәгазь яки сатып алучылар өчен ачык булган башка мәгълүмат чыганагында ясарга, шул исәптән грифель такталары, стендлар, яктырткыч таблолар кулланып, мәгълүматның электрон чагылышын файдаланырга мөмкин.»;

3) 2.12. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12. Контроль-касса техникасы кулланмыйча түләү карталары файдаланып акчалата исәп-хисап һәм (яки) исәп-хисап башкаручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр сатып алучы (клиент) таләбе буенча тиешле товар (эш, хезмәт күрсәтү) өчен акча алуны раслаучы документ – товар чегы, квитанция яки башка документ бирергә тиеш. Әлеге документ товар (эш, хезмәт күрсәтү) өчен түләгән вакытта бирелә һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

а) документның исеме, алты урынлы номер һәм серия;

б) исеме һәм оештыру-хокукый формасы – оешмалар өчен; фамилия, исем, әтисенең исеме – шәхси эшмәкәрләр өчен;

в) юридик затның даими гамәлдә булган башкарма органының урнашу урыны (юридик затның даими гамәлдәге башкарма органының урнашу урыны булмаган очракта – юридик зат исеменнән килешүсез эш итәргә хокукы булган башка орган яки затның);

г) документ биргән оешмага (шәхси эшмәкәргә) бирелгән салым түләүченең идентификация номеры;

д) хезмәт күрсәтү төре;

е) хезмәт күрсәтүнең акчалата күләме;

ж) акчалата һәм (яки) түләү картасыннан файдаланып түләү күләме;

з) түләү һәм документ төзү датасы;

и) операция башкару һәм аны дөрес итеп рәсмиләштерү өчен җаваплы затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме һәм әтисенең исеме, аның шәхси имзасы, оешманың (шәхси эшмәкәрнең) печате;

к) хезмәт күрсәтү спецификасын тасвирлаучы һәм оешма (шәхси эшмәкәр) өстәргә хокуклы булган башка реквизитлар.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карар бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Үрнәк авыл җирлеге башлыгы: И.Р.Камалетдинов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «УРНЯКСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ОГРН1121690080284
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН1609012727